**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «17» сентябреннән № 202

Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне раслау турында

Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү хокукына ия муниципаль учреждениеләрнең үтенечнамәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2025-20256 уку елына Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү хокукы булган муниципаль учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне кушымтага нигезләнеп расларга

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенә әлеге карарны «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик бәяне раслау турында» 2024 елның 10 октябрендәге 252 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Е.А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «17» сентябреннән
202 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәзакон нигезендә халыкка түләүле хезмәтләр күрсәтү хокукына ия булган муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан халыкка күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр өчен чик бәя

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сумнарда |
|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре | | | |
| 1 | Нәфис-эстетик цикл | 30 минут | 350,00 |
| 2 | Физкультура-сәламәтләндерү юнәлеше | 30 минут | 350,00 |
| 3 | Сәламәтләндерү һәм медицина хезмәтләре | 30 минут | 350,00 |
| 4 | Психолог белән дәресләр | 30 минут | 350,00 |
| 5 | Логопед белән дәресләр | 30 минут | 350,00 |
| 6 | Ял көне төркеме | 6 сәгать | 400,00 |
| 7 | Гомуми интеллектуаль юнәлеш | 30 минут | 350,00 |